КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 12 март г.Казань № 126

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе тарафыннан башкарыла торган фәнни-гамәли тикшеренүләрне оештыру нәтиҗәлелеген күтәрү һәм яраштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 6 декабрь, 1061 нче; 2013 ел, 21 май, 335 нче; 2014 ел, 16 октябрь, 763 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1095 нче; 2015 ел, 25 сентябрь, 709 нчы; 2017 ел, 27 ноябрь, 918 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның беренче абзацында «һәм бу Уставның 3 нче кушымтасы нигезендә төбәк бүлекләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

3.1.3 пунктта җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.2.5 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

3.2.10 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

3.4.4 пунктның унбишенче абзацында «, шулай ук Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең төбәк бүлекләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.6.7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4.8 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

Уставның 2 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Цифрлы технологияләр үзәге.»;

әлеге Уставның 3 нче кушымтасы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин